ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авыл
җирлеге Советы

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Нижнеберескинского
сельского поселения
Атнинского муниципального района

422743, ТР Әтнә муниципаль районы,
Түбән Бәрәскә авылы, Совет урамы, 17а
тел. 33-4-05, тел./факс 33-4-03

422743, РТ, Атнинский муниципальный
район, село Нижняя Береске, улица
Совета, д. 17а
тел. 33-4-05, тел./факс 33-4-03

**КАРАР**

3 ноябрь 2022 ел № 3

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге
Олы Бәрәзә торак пунктында
гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законының 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. 2022 елның 14 ноябренә 14.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Бәрәзә торак пунктының Большая, Центральная, Таллык, Чишмәле, Строителей, М.Җәлил урамнарында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2022 елның 15 ноябренә 14.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Бәрәзә торак пунктының Зеленая, Ленин, Чүлмәнчек, Тукай, С.Хәким, Яшьлек, Школьная урамнарында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл башкарма комитеты;
- гражданнар җыенының беренче этабын үткәрү вакыты – 14 ноябрь 2022 ел 14.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр;
- гражданнар җыенының икенче этабын үткәрү вакыты – 15 ноябрь 2022 ел 14.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр;
- гражданнар җыенының беренче этабын үткәрү урыны – Олы Бәрәзә авылы, Большая ур., 37а нче йорт, күпфункцияле үзәк янында;
- гражданнар җыенының икенче этабын үткәрү урыны – Олы Бәрәзә авылы, С.Хәким ур.,11 нче йорт янында.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл башкарма комитетына тәкъдим итергә:

- 2022 елның 9 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Түбән Бәрәскә авылы, Совет урамы, 17а йорт;
- сайлау хокукына ия булган Олы Бәрәзә торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;
- Олы Бәрәзә торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итергә.

5. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Сез 2023 елда Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Бәрәзә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Олы Бәрәзә авылы территориясен чистарту (үлән чабу, агач һәм куакларны кисү);

2) урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү (лампочкаларны, үткәргечләрне ремонтлау, алыштыру) һәм лампочкалар сатып алу;

3) зират территориясен чистарту, агач һәм куакларны кисү (килешү буенча эш һәм хезмәт өчен түләү);

4) урам юллары өслекләрен ремонтлау һәм төзекләндерү (вак таш сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәт өчен түләү).

5) Олы Бәрәзә авылында урам юлларын кардан чистарту, грейдерлау (килешү буенча эш һәм хезмәт өчен түләү).

"РИЗА" "КАРШЫ"

6. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм ТР Әтнә муниципаль районы, Түбән Бәрәскә авылы, Совет урамы, 17а йорт адресы буенча урнашкан Түбән Бәрәскә авыл җирлеге бинасында мәгълүмат стендында; ТР Әтнә муниципаль районы, Олы Бәрәзә авылы, Большая урамы, 37а йорт, авыл клубы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы: Фатыхова А.В.

Совет Нижнеберескинского сельского поселения
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы
ИНН 1610000476
ОГРН 1021606155405
АТНИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ